БАШКАРМА
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Татарстан Республикасы

ӘГӘРҖӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНҢ
БАШКОРТМА КОМИТЕТЛАР

Гагарин ур.13, Әгәрҗе шәһәре, 422230

Гагарин ур., 13 йорт, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**КАРАР** **КАРАР**

«17» июня 2019 г. № 289

2019 елда чыгарылыш кичәсен үткәрү турында

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2019 елның 22 мартыннан № под-485/19 санлы “Татарстан Республикасында 2018/2019 уку елын тәмамлау һәм гомуми белем бирү оешмаларының IX, XI сыйныф чыгарылыш укучыларының дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм үткәрү турында" Боерыгына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Район чыгарылыш кичәсен 2019 елның 25 июнендә 13.00-17.30 сәг Район мәдәният йортында, «Яшьлек " паркында һәм Җиңү мәйданында үткәрергә.

2. 1нче кушымтада беркетелгән чыгарылыш кичәсен үткәрү программасын расларга.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе башлыгы В.Г.Сафиуллинага:

3.1. Әгерҗе шәһәре һәм авыл мәктәпләренең 11 сыйныф укучыларын әлеге чарага чакырырга;

3.2 аларны чара үткәрү урынына алып баруны тәэмин итәргә;

3.3. чараны әзерләү һәм үткәрү буенча җаваплы затларны билгеләргә.

4. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре бүлеге начальнигы Т.С.Сергеевага программа нигезендә чыгарылыш укучылар өчен «Яшьлек» паркында гомуми җыелыш һәм аларның Җиңү мәйданына кадәр парадын оештырырга.

5. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге начальнигы М.М.Гатауллинга чараны үткәрү өчен бина бирергә һәм шартлар тудырырга.

6. Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча бүлеге начальнигы А.З.Вәлиевка чараны үткәрү урыннарында җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итәргә һәм чара үткәрү вакытында К.Маркс урамы буенча төп юлны ябуны оештырырга тәкъдим итәргә.

7. Әгерҗе район үзәк хастаханәсенең баш табибы Э.В.Овчинниковка чара уздыру вакытында медицина ярдәме күрсәтүне оештыруны тәкъдим итәргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

9. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Р.Р.Гильмутдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А. С. Авдеев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
17.06.2019 № 229санлы
карарына
1нче кушымта

**11 нче сыйныфны тәмамлаучылар өчен тантаналы чара үткәрү программасы**

| номерлы | Үткәрү вакыты | Чараның исеме | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | 13.00 – 14.30 | Район мәдәният сараенда авыл мәктәпләренең 11 сыйныф укучыларына тантаналы рәвештә аттестатлар тапшыру | Мәгариф идарәсе - мәдәният бүлеге (килешү буенча) |
| 2 | 14.30-15.30 | "Яшьлек” паркында гомуми җыелыш, 11 сыйныф укучылары өчен фотосессия, интервью | Яшьләр эшләре бүлеге (килешү буенча) |
| 3 | 15.30-16.00 | «Яшьлек» паркыннан Җиңү мәйданына кадәр чыгарылыш сыйныф укучылары парады | Яшьләр эшләре бүлеге (килешү буенча) |
| 4 | 16.00-17.30 | 11 нче сыйныф укучылары өчен Җиңү мәйданында тантаналы чара | Мәгариф идарәсе - мәдәният бүлеге (килешү буенча) |